МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.05.2021 г.Казань № 327

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 7 июнендә 7709 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм радиоактив калдыкларның Тичә елгасына эләгү нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2012 елның 19 июлендәге 576 номерлы боерыгы белән расланган 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм радиоактив калдыкларның Тичә елгасына эләгү нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм радиоактив калдыкларның Тичә елгасына эләгү нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2012 елның 19

июлендәге 576 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.07.2016 №442, 08.06.2017 №348, 07.05.2018 №357, 19.09.2018 №887, 26.07.2019 №580, 15.11.2019 №1031, 14.07.2020 №518, 09.10.2020 №715 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм радиоактив калдыкларның Тичә елгасына элэгү нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 20 маендагы 327 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм радиоактив калдыкларның Тичә елгасына эләгү нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2012 елның 19 июлендәге 576 номерлы боерыгы белән расланган 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм радиоактив калдыкларның Тичә елгасына эләгү нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графалары:

өченче абзацта «гражданлык хәле актларын теркәү органнарында» сүзләрен «вәкаләтле органнарда» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «гражданлык хәле актларын теркәү органнарында» сүзләрен «вәкаләтле органнарда» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктта:

бишенче абзацта «гражданлык хәле актларын теркәү органнарында» сүзләрен «вәкаләтле органга;» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «гражданлык хәле актларын теркәү органнарында» сүзләрен «вәкаләтле органга» сүзләренә алмаштырырга;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.».